# «Буран әбиләре» татарча да җырлады

25 майда Лаеш районының Никольское авылында XXII Бөтенрусия «Каравон» урыс фольклоры фестивале булып узды. Быел анда Удмуртиядән танылган «Буран әбиләре» ансамбле дә катнашты. Барлыгы фестивальдә Татарстан, Мари Иле, Чуашстан, Киров өлкәсе, Мәскәүдән 148 фольклор коллективы чыгыш ясады.

«Каравон» кунакларын беренчеләрдән булып Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин сәламләде.

- Мондый бәйрәмнәрнең кыйммәте бик зур, чөнки илдә-көндә татулык булганда гына бәхеткә ирешеп була, - диде ул.

Аннары Ф.Мөхәммәтшин Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның фестивальдә катнашучыларга һәм кунакларга мөрәҗәгатен укып ирештерде. «Төрле милләт һәм төрле дин вәкилләрен елдан-ел үзенә күбрәк җәлеп иткән «Каравон» бүген Татарстанда гына түгел, ә аннан читтә дә киң танылды. «Каравон»ның ватаны - Урыс Никольское авылында халык традицияләре белән берләштән рухи-әхлакый кыйммәтләрнең үсә баруы да яхшы күрсәткеч булып тора. «Каравон» мисалында урыс халкының иҗади мөмкинлекләре никадәр киң булуын, аның тынычлыкка, матурлыкка, гармониягә һәм бердәмлеккә омтылышының көчле икәнен тагын бер тапкыр аңлыйсың», - дигән Илбаш.

Спикерыбыз Ф.Мөхәммәтшин республикабыз Президенты исеменнән Никольское авылы иҗат коллективларына автобус бүләк итте.

Лаеш районы башлыгы Михаил Афанасьев үз чыгышында Мәдәният елында үткәреләгән «Каравон» бәйрәменең әһәмияте тагын да зуррак булуын билгеләп үтте.

«Буран әбиләре» тамашачыны удмурт, чит ил һәм хәтта ки бер татар җыры белән куандырып кына калмады, республикабыз Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинга удмурт бәләзмә, чабата һәм футболкалар бүләк итте.

- Быел "Евровидение" халыкара бәйгесендә мыек-сакаллы хатын-кыз җиңгәч, үзебезнең «Буран әбиләре» өчен тагын бер кат сөенеп куйдым, чөнки алар җырлый белү өстенә, әле әхлак тәрбияли, традицияләрне саклый һәм үстерә, - диде аларга җавап итеп Ф.Мөхәммәтшин.

Әбиләрнең әйтүенә караганда, бүгенге көндә Удмуртиянең Бураново авылында Татарстан ярдәме белән гыйбадәт йорты төзелә икән. «Буран әбиләре» коллективы «Каравон» бәйрәмендә чыгыш ясаган өчен гонорарны да шул төзелешкә бирергә вәгъдә итте. Фестиваль үтүгә, «Буран әбиләре» Красноярскига гастрольгә китте.

«Каравон» фестивалендә һәркем үзе теләгәнчә күңел ача, ял итә алды. Теләгәне - җырлады, биеде, театраль тамашалар карады, борынгы урыс уеннарында, бәйгеләрдә катнашты. «Осталар шәһәрчеге»ндә гамәли-бизәнү сәнгате әйберләрен сатып алырга мөмкин иде. Балалар исә «Әкият» Татар дәүләт курчак театры артистлары чыгышын карады, төрле аттракционнарда катнашты.

Фестиваль зур әйлән-бәйлән белән тәмамланды.



● «Буран әбиләре» чыгыш ясый.

Шамил АБДЮШЕВ фотосы.

# Шагыйрьгә Мәхтүмколый медале

Төркмәнстан башкаласында төркмән әдәбияте классигы Мәхтүмколый Фирагинең татар телендә Казанда чыккан китабын тәкъдим итү булды. Әлеге чарада XVIII гасырда яшәп иҗат иткән төркмән мәгърифәтчесенең мирасын татарчага тәрҗемә итүчеләрнең берсе, китапны төзүче Роберт Миңнуллин катнашты.

Көнчыгышның иң атаклы галимнәреннән берсе саналган Мәхтүмколыйның юбилеена багышланган китапның беренче нөсхәсен апрель азагында Төркмәнстанга сәфәре вакытында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Президент Гурбангулы Бердымөхәммәдовка бүләк иткән иде.

Бу көннәрдә Ашхабадта төркмән халкының бөек улына багышланган күп кенә чаралар уза һәм китаплар чыгарыла.Шундый китаплар арасында татарча чыккан җыентык та бар. Ошбу басма Төркмәнстанның Халыкара мөнәсәбәтләр институтында "Мәхтүмколый Фираги һәм гомумкешелек мәдәни кыйммәтләре" дигән халыкара конференция кысаларында дөньяның күп илләреннән килгән делегацияләр катнашында тәкъдим ителде.

Әлеге чарада катнашучыларга сәлам сүзләре белән Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин мөрәҗәгать итте.Төркмәнстан Президентына Мәхтүмколыйның бай мирасын өйрәнү һәм пропагандалауга ярдәм иткәне өчен рәхмәт белдереп, татар шагыйре төркмән мәгърифәтчесенең туган халкының гына түгел, ә барлык Көнчыгыш халыкларының да рухи дөньясына йогынты ясавын билгеләп үтте.

Китапны тәкъдим итү тантанасында Төркмәнстан Министрлар Кабинеты Рәисе урынбасары С.Тойлыев, Төркмәнстан демократик партиясе рәисе К.Бабаев, Төркмәнстан Фәннәр академиясенең Тел һәм әдәбият институты директоры К. Кыуасова, халык шагыйре Г.Шагулыева, "Төркмәнстан" гәзите баш мөхәррире К.Рәҗәбов һ.б. чыгыш ясады.

Шунысын да искәртик, Төркмәнстан Президенты Указы нигезендә, Роберт Миңнуллин Мәхтүмколый Фираги медале белән бүләкләнде. Указда әйтелгәнчә, шагыйрь әлеге бүләккә төркмән халкының бөек галиме Мәхтүмколый Фирагинең иҗади мирасын популярлаштырудагы казанышлары һәм Төркмәнстан белән Татарстан арасында дуслык мөнәсәбәтләрен үстерүгә өлеш керткән өчен лаек булган.

## «Золушка» нәни тамашачыларны көтә

31 майда «Әкият» Татар дәүләт курчак театры нәни тамашачыларга Е.Шварц пьесасы буенча куелган «Золушка» спектаклен тәкъдим итә. Аны талантлы яшь артист Рафаэль Таһиров сәхнәләштерә. Бүгенге көндә ул Санкт-Петербург дәүләт театр сәнгате академиясенең режиссура кафедрасында белем ала. Спектакльне сәхнәгә куючы рәссам Екатерина Спиридонова да шушы ук уку йортын тәмамлаган. Һәр икесе өчен дә «Золушка» - иҗат юлларындагы тәүге спектакль. Тамашада музыка, җыр, биюләргә зур урын бирелә. Өстәвенә, бөтен сәхнә бизәлешләре дә төрле музыка уен коралларына охшатып эшләнгән.

## "Нәүрүз" якынлаша

2-8 июньдә башкалабызда III халыкара "Нәүрүз" театраль-белем бирү фестиваль-форумы уздырыла. Анда Татарстан, Русия, Австрия, Бангладеш, Белоруссия, Бельгия, Германия, Греция, Словакия, АКШ, Франциядәге 30лап театрдан 166 театр әһеленең катнашуы көтелә. Форумга 15ләп педагог килачәк. Алар "Актерлык сәнгате һәм гамәли режиссура", "Режиссура теориясе, сценография һәм музыкаль театр", "Заман театры, менеджмент, пиар, хокук белеме", "Курчак театры сәнгате", "Театр тәнкыйте" дигән темаларга һәркайсы үз семинарын тәкъдим итәргә җыена. Форумга белем, күнекмәләр алырга килгән артист, режиссерларга, театр директорларына, сәхнә бизәүче рәссамнарга педагогик сайлыйсы гына кала.

Бу көннәрдә П.Ойунский исемендәге Саха академия театрының "Хыялдагы зәңгәр диңгез ярым", Саха (Якутия) Олонхо автоном театрының "Удаган кызлар", Г.Камал театрының "Җәйнең бер көнендә", "Банкрот", "Мулла", "Ричард III" спектакльләрен күрсәтү дә күздә тотыла.

## Остазны олылау

КФУның Филология һәм мәдиниятара багланышлар институты актлар залында филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан һәм Русиянең атказанган фән эшлеклесе, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Дәүләт бүләге иясе Хатыйп Миңнегуловка 75 яшь тулу уңаеннан "Гомерем мизгелләре" исемле әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Юбилярны Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Р.Вәлиев, КФУ президенты М.Сәлахов, ФМБИ директоры Р. Җамалетдинов, ТР Фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркәтибе Д. Заһидуллина, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе башлыгы Л.Әхмәтҗанова һ.б. котлады.

Белгебезчә, Х.Миңнегулов, нигездә, Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәбиятен, Шәрекъ классикасы белән тарихи багланышларны өйрәнгән галим. Аның шулай ук XX гасыр татар әдәбияте, чит илләрдәге татар сүз сәнгате, әдәбиятне укыту методикасы, әдәбият теориясе, текстология, халык һәм дин тарихы, мәдәният һәм мәгариф проблемаларына багышланган мөһим хезмәтләре бар.

Ул – татар, урыс, төрек, төркмән һ.б. телләрдә дөнья күргән 30дан артык китап, 600дән күбрәк мәкалә авторы. Галим 30 томлы төрки дөнья әдәбиятләре тарихын язуда, антологиясен төзүдә (бу китаплар Анкарада төрек телендә нәшер ителә) автор һәм татар әдәбиятчеләре төркеменең җитәкчесе буларак катнаша. Х.Миңнегулов Мәскәү, Истанбул, Анкара, Һелсинки, Ташкент, Алма-Ата, Санкт-Петербург, Төмән һ.б. шәһәрләргә лекцияләр укырга барып йөри, конференция, конгресс, симпозиумнарда докладлар белән чыгышлар ясый.

Без Хатыйп ага Миңнегуловны күркәм гомер бәйрәме белән котлап, аңа исәнлек-саулык, тигез гомер, фәнни уңышлар һәм сүнмәс-сүрелмәс иҗат дәрте теләп калабыз.




✔ Дөньяда иң кыска коммерция авиарейсы Папуа утравындагы Индонезия авыллары Кегата һәм Аповоны тоташтыра - алар арасында очыш нибары 73 секунд дәвам итә.

✔ Кытайда 80 яшьлек Жуань Пан инде 14 ел рәттән кешеләргә файдалы эш белән шөгыльләнә - чебен үтергеч белән көненә 8әр сәгать буе чебен үтереп йөри, көненә 1 меңләп бөҗәкнең башына җитә.

✔ Кешенең ашказаны согындагы кислоталар шулкадәр куәтле ки, алар берничә көн эчендә ашказаны тышчасын тулысынча ашап бетерергә сәләтле. Шунлыктан һәр 3-4 көн саен ашказанында яңа лайлалы тышча ясала.